ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

08 август 2025 ел номер 1495

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Никольский урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен «Лев Николаевич Толстой исемендәге этномәдәни рус компонентлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе итеп үзгәртү һәм уставны яңа редакциядә раслау турында**

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның рус җәмәгатьчелеге вәкилләре белән очрашу йомгаклары буенча 2025 елның 23 июнендәге ПР-129 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 2.1 пункты нигезендә, «РФдә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» РФ Федераль Законының 6 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртү һәм бетерү тәртибен раслау, шулай ук район муниципаль учреждениеләре уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 13 декабрендәге 2031 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Никольский урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе исемен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лев Николаевич Толстой исемендәге этномәдәни рус компонентлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба - Учреждение)итеп үзгәртергә.

3. Учреждение Уставын яңа редакциядә расларга.

4. Учреждение директоры Перванаева Ирина Владимировнага уставка үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә теркәргә, дәүләт теркәве турында гариза биргәндә мөрәҗәгать итүче булырга һәм рөхсәт документларын үзгәрешләргә туры

китерергә.

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль учреждениесенең «Никольский урта гомуми белем бирү мәктәбе «МБМУ Уставын яңа редакциядә раслау турында» 2019 елның 18 мартындагы 549 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Л. И. Хөсәеновага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**